**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

№ 14/1 «24» август 2016 ел

ТР Тукай муниципаль районы
Иске Дөреш авыл җирлегендә муниципаль
хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Тукай районы прокурорының 2016 елның 27 июнендәге 02-08-02 номерлы протесты нигезендә, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 03.12.2012 №230-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон шулай ук Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында кодекс нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1) 1 өлешнең 1.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

ТР Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт РФ Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 елдагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шулай ук «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 28.07.2004 елның 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашырыла;

2) 2 өлешнең 2.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

2.5. Җирлектә муниципаль хезмәт вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнарга квалификация таләпләренә туры килергә кирәк.

Әлеге статья максатларында муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәр һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт вазыйфаларында һәм федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында һәм башка төрләрдәге вазыйфаларда дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында эш стажы да исәпкә алына

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә кирәк булган һөнәри белемнәргә һәм

аларны куллану күнекмәләренә квалификация таләпләре Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Нигезләмә нигезендә муниципаль органнарның җирле үзидарә органнарының хокукый актлары белән билгеләнә.

3) 4.3 статьяның 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт вазыйфасына беренче тапкыр билгеләнүче муниципаль хезмәткәрләргә 3 класс чины бирелә».

Муниципаль хезмәткәргә чираттагы классы чин биргәндә федераль дәүләт хезмәтенең тиешле классы чинында, дипломатик рангта, хәрби яки махсус исемдә, дәүләт граждан хезмәтенең классы чинендә, муниципаль хезмәтнең квалификация разрядында булу дәвамлылыгы исәпкә алына.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек депутаты Ф.Ф.Закиров